**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» август, 2022 ел № 525

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 28 декабрендәге 2065 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.36 статьялары нигезендә «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында» 2019 елның 17 июнендәге 498 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 22 декабрендәге 111-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент уздыру турында» 2018 елның 27 декабрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 28 декабрендәге 2065 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 II пунктның б) пунктчасы. Төп төшенчәләрне һәм аларның билгеләмәләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

хуҗалык итүче субъект - сәүдә субъекты - юридик зат яисә эшкуар, индивидуаль « Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар, сәүдә белән шөгыльләнүче һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән затлар;

1.2 4.14.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: стационар булмаган сәүдә объектын аукцион үткәрмичә төзелә торган урнаштыру шартнамәсе буенча еллык түләү күләме бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә урнаштыру хокукын бәяләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре рәисе И.Р. Дәүләтхановка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин